| СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

РЕШЕНИЕ КАРАР

29.09.2023 Баулы шәһәре № 218

Баулы муниципаль районы Советының 2022 елның 14 сентябрендәге 130 номерлы “Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүмат бирү турындагы Нигезләмәне раслау турында” карарына үзгәрешләр кертү турында

“Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә Баулы муниципаль район Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Баулы муниципаль районы Советының 2022 елның 14 сентябрендәге 130 номерлы “Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүмат бирү турындагы Нигезләмәне раслау турында” карарына түбәндәге үзгәреш кертергә:

16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында ялган мәгълүматлар тапшырмаган яки биргән очракта гражданин муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнә алмый, ә муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәттә кала алмый һәм эштән азат ителергә тиеш.

Муниципаль хезмәткәрләрнең үз чыгымнары турында мәгълүматләр бирмәү, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, белә торып тулы булмаган мәгълүмат бирү, яисә үз чыгымнары турында белә торып дөрес булмаган мәгъматләр бирү

яисә тормыш иптәше (ире) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр бирмәү, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, белә торып тулы булмаган мәгълүматләр бирү яисә хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында дөрес булмаган мәгълүматлар, әгәр мондый мәгълүматларны тапшыру мәҗбүри булса, аларны алмаштырып торган вазыйфаларыннан азат итүгә, муниципаль хезмәттән билгеләнгән тәртиптә эштән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат Рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Советының җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
Район Советы Рәисе И.И. Гозеров